КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 18 гыйнвар г.Казань № 20

Зәй муниципаль районында җир кишәрлеген бер категориядән икенче категориягә күчерү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, «Татнефтеотдача» акционерлар җәмгыятенең Зәй муниципаль районында урнашкан, «Татнефтеотдача» акционерлар җәмгыяте милкендә булган 0,0862 гектар мәйданлы авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җир кишәрлеген 16:19:190205:77 кадастр саны белән Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан күчермәләрдә күрсәтелгән чикләрдә җир асты байлыкларыннан файдалану максатларында сәнәгать җирләре һәм башка махсус әһәмияттәге җирләр категориясенә күчерү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына билгеләнгән тәртиптә тиешле үзгәрешләр кертүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин